| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МЕНДЕЛЕЕВСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МЕНДЕЛЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК ШӘҺӘР<br>СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.11.2024 ел №82

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре бюджеты турында

1 статья

1. 2025 елга беренче укылышта Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре бюджеты керемнәренең гомуми күләме 103786,80 мең сум;

2) Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 103786,80 мең сум.

3) Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре бюджеты кытлыгы 0 сум күләмендә

2. 2026, 2027 елларга беренче укылышта Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) 2026 елга Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре бюджеты керемнәренең гомуми күләме 102971,70 мең сум һәм 2027 елга 106280,10 мең сум;

2) Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре бюджеты чыгымнарының гомуми күләме:

- 2026 елга 102971,70 мең сум, шул исәптән шартлы расланган чыгымнар 2574,29 мең сум;

- 2027 елга 106280,10 мең сум, шул исәптән шартлы расланган чыгымнар 5314,00 мең сум.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын расларга:

- 2025 елга һәм 2026 и 2027 еллар план чорына әлеге карарга 1 кушымта нигезендә.

2 статья

1. 2026 елның 1 гыйнварына Менделеевск муниципаль районының бурыч

йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның югары чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 сум күләмендә расларга

2. 2027 елның 1 гыйнварына Менделеевск муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның югары чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 сум күләмендә расларга

3. 2028 елның 1 гыйнварына Менделеевск муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның югары чиген 0 сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 сум күләмендә расларга

3 статья

1. Менделеевск муниципаль районы бюджетында әлеге карарга 2 кушымта нигезендә 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына фаразланган керем күләмен исәпкә алырга.

4 статья

1. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Менделеевск муниципаль районы чыгымнарының 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына ведомство структурасын әлеге карарга 4 кушымта нигезендә расларга.

5 статья

Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре бюджетында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен расларга:

- 2025 елга 9274,80 мең сум;
- 2026 елга 2928,20 мең сум;
- 2027 елга 1202,80 мең сум.

6 статья

1. Торак фондын капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыру вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетларыннан Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы бюджетына күчерелә торган башка бюджетара трансфертлар күләмен расларга:

- 2025 елга 12919,000 мең сум;
- 2026 елга 12919,000 мең сум;
- 2027 елга 12919,000 мең сум.

2. Менделеевск муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертларны еллык ассигнованиеләрдән ай саен тигез өлешләр белән күчерүне тәэмин итәргә.

7 статья

1. Авыл җирлекләре бюджетларыннан Менделеевск муниципаль районы бюджетына күчерелә торган субсидия күләмен расларга:

- 2025 елга 66708,10 мең сум;
- 2026 елга 65146,60 мең сум;

- 2027 елга 68365,00 мең сум.

2. Менделеевск муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертларны еллык ассигнованиеләрдән ай саен тигез өлешләр белән күчерүне тәэмин итәргә.

8 статья

1. Җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренең санын арттыруга, шулай ук аларны тоту чыгымнарын арттыруга китерә торган карарларны 2025 елда кабул итәргә хокуклы түгел.

9 статья

2025 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре бюджетының калган акчалары, әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2024 елда түләнергә тиешле товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар өчен түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә 2025 елның 1 гыйнварына әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә әлеге максатларга түләнергә тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен 2025 елда җибәрелә.

10 статья

Татарстан Республикасы Менделеевск районы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты территориаль бүлекчәсе төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре бюджетын үтәү буенча аерым функцияләр башкара.

11 статья

Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: www.mendeleevsk.tatarstan.ru.

12 статья

Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Шәһәр Советы рәисе Р.И. Беляев